ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2019 г.Мензелинск № 10

2019 елга
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында
вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 06 октябендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Татарстан Республикасында кабер казу һәм җирләү эше турында"гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.05.2007 елдагы "Татарстан Республикасында кабер казу һәм җирләү эше турында"гы Федераль законын тормышка ашыру буенча чаралар турында"гы №196 карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24 гыйнвар, 2019елдагы "2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында"гы №32 карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Кушымта №1 һәм Кушымта №2 нигезендә, 2019 елның 1 февраленнән Минзәлә муниципаль районында вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Гамәлдәге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе К.Р.Нәҗмиевка, Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Минзәлә муниципаль
район башлыгы А.Ф.Салахов.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башлыгы карарына
Кушымта № 1
дата 31.01.2019 ел. № 10

2019 елның 1 февраленнән
Минзәлә муниципаль районында
вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм урынына илтү | 1828,54 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 767,95 |
| 4.Җирләү (кабер казу һәм вафат булучыны җирләү) | 3349,98 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы - А.Ф.Салахов

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башлыгы карарына
Кушымта № 2
дата 31.01.2019 ел. № 10

2019 елның 1 февраленнән
Минзәлә муниципаль районында
вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне киендерү | 231,87 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм урынына илтү | 1322,73 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 767,95 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм вафат булучыны җирләү) | 3623,92 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Минзәлә муниципаль
район башлыгы - А.Ф.Салахов.